**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**ФЕДОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ФЕДОРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 57-0-15, факс 57-0-15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**28 .10. 2025** **№ 3**

**2026 елда гражданнарга үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлегенең Удельное Нечасово торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Федоровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм::

1. 2025 елның 13 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Удельно-Нечасово авыл мәдәният йорты бинасында, Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Удельное Нечасово авылы, Ленин урамы, 31 йорт, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлегенең Удельное Нечасово торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлегенең Удельное Нечасово торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, ирektән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан, махсус хәрби операция (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекleләр) һәм аларның гаилә әгъзалары, атап әйткәндә: ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балаларны; гаилә әгъзаларын, атап әйткәндә: ата-аналарны, ир белән хатынны, балигъ булган балаларны, махсус хәрби операциядә һәлак булган катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекleләр) һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Удельное Нечасово торак пунктында су чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Удельное Нечасово торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (фонарьлар сатып алу,урнаштыру) ремонтлауны?».

» КАРШЫ «РИЗА”

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Федоровка авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **М.Ю. Никонорова**